РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

19.01.2024 — № 1

**Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының 2019 елның 6 маендагы 32 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Саба районы прокуратурасының протестын карап,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 6 маендагы 32 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлектәге 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. «7. Исәп-хисап чорында хезмәт дисциплинасын бозган өчен дисциплинар һәм матди җаваплылыкка тартылган түбәндәге очракларда бухгалтерларга премияләр түләнми:

– сәбәпсез эш калдыру;
– соңга калу;
– турыдан-туры җитәкченең боерыгын үтәмәү;
– алкоголь, наркотик, токсик хәләттә эшкә килү;
– эш бирүченең милкен югалту яки бозу;

– билгеләнгән хезмәт нормаларын үтәмәү, йөкләмәләрне үтәү срокларын бозу.

Бухгалтердан алынмаган дисциплинар җәза булганда премия күләме 50% ка кими.

Әгәр премия түләнгәннән соң хокук бозулар ачыкланса, премиядән мәхрүм итү хокук бозулар ачыкланган исәп-хисап чорында башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге Башлыгы Т.Р. Шәмсиев